ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.03.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**873**

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге, 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында»1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 номерлы РФ Законының 13 ст., «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 08 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы ТР Законының 6 ст., «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2025 елның 29 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы ТР Законы белән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты 2026 елның 13 иартындагы 873 номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартларын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү).

2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алучылар: Россия Федерациясенең «Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге №1761-1 номерлы Законы нигезендә торак урыннар алу хокукы булган гаилә әгъзалары исеменнән гариза белән мөрәҗәгать иткән Татарстан Республикасы территориясендә (репрессия кулланылганчы үзе яшәгән урыннарга һәм торак пунктларга) элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессиягә бәйле рәвештә торак урынын югалткан реабилитацияләнгән граждан (алга таба — мөрәҗәгать итүче) .

Мөрәҗәгать итүчеләр мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) яклый ала.

3. Муниципаль хезмәт мөрәҗәгать итүчегә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) бердәм порталы» (https://www.gosuslugi.ru) федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштырылган мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) буенча күрсәтелергә тиеш.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы

4. Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме

5. Муниципаль хезмәтне Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) күрсәтә.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып «Зеленодольск муниципаль районы Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлеге белгече тора.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Мөрәҗәгать итүче «Исәпкә алу турында карар» сорап мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) торак урын бирелүгә мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу турында карар (7 нче кушымта);

2) торак урын бирелүгә мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алудан баш тарту турында карар (8 нче кушымта).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Башкарма комитеты җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының (www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы, Бердәм портал) шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба – КФҮ) Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә алынырга мөмкин. Шулай ук мөрәҗәгать итүче сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүче күрсәткән адрес буенча почта аша җибәреп, кәгазь чыганактагы таныкланган күчермә рәвешендә я мөрәҗәгать итүче күрсәткән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә алынырга мөмкин.

10. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә яисә электрон документның нөсхәсен кәгазь саклагычта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы

11. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - 10 эш көненнән дә артмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.

12.Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктатып тору - мөрәҗәгать итүче документларны рәсмиләштерү буенча ачыкланган кисәтүләр турында хәбәрнамә алган һәм (яисә) документлар тапшырылмаган көннән алып 30 календарь көн.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ рәвешендә җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла

13. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны Башкарма комитетта һәм КФҮдә бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

14. Документларны рәсмиләштерү буенча ачыкланган кисәтүләр турында хәбәрнамә алган һәм (яисә) документлар тапшырылмаган көннән алып 30 календарь көн узгач документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

15. Документларны рәсмиләштерү буенча ачыкланган кисәтүләр һәм (яисә) документларны тапшырмау муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

16. Мөрәҗәгать итүче категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

19. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

Хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать иткәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

20. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты - 15 минуттан артмаска тиеш.

21. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы

22. КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза тапшырылган көнне КФҮ АМСсыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән раслама бирелә.

23. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номерын һәм гариза бирү датасын күрсәтеп, гариза җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала.

24. Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаны ике нөсхәдә тапшырган көнне, Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документлар күрсәтелгән бер нөсхәсе кире кайтарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

25. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

26. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатыннан түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (биналарга/биналардан уңайлы керү/чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү);

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында урнаштырылган визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе тотрыклы бозылулары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетеп һәм күреп була торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне, башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктала Брайль шрифтын кулланып башкарылган билгеләр белән кабатлап бирү;

5) сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге «Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документ булган очракта, юл күрсәтүче этне кертергә рөхсәт итү.

27. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм Регламентның 26 пунктының 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

28. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә куела торган таләпләр турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында, КФҮдә, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре

29. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;

кирәкле белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуда комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срогын үтәү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срокларын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән үзара эшчәнлеге барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырганда бер мәртәбә гамәлгә ашырыла;

4.2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документның нөсхәсе рәвешендә КФҮдә алу кирәк булган очракта, бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер тапкыр аралашу озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы, терминаль җайланмалар ярдәмендә бәяләргә хокуклы.

31. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда яки Республика порталында шәхси кабинетында, күп функцияле үзәктә алынырга мөмкин.

32. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮтә аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

33. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүне комплекслы рәсми мөрәҗәгать составында алырга хокуклы.

34. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы күрсәткечләре турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында, кФҮ, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр

35. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары 8 элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) муниципаль хезмәтне күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларның барышы һәм үтәлеше турында белешмәләр алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын Бердәм портал, Республика порталы аша бәяләргә;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазифаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә башкарылган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Бердәм портал, Республика порталы, судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша Башкарма комитетның, шулай ук аның вазифа затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерергә.

36. Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда,  Республика порталында, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада бирү зарурлыгыннан башка, электрон форманы тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

37. КФҮтә  мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү буенча язу (алга таба - язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ контакт-үзәге телефоны (8 843 222 06 20) аша алып барыла. Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Бердәм портал, Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә  система тарафыннан соратып алына торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

кабул итү буенча теләгән көнен һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу вакытында хәбәр ителгән белешмәләр шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче тапшырган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән кабул итү вакытыннан соң 15 минут үткәч килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында аңа мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылудан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән,  Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы аралыгын исәпләп чыгару өчен кирәк булган белешмәләр бирүдән тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларның тулы исемлеге

38. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар түбәндәгечә бүленә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга хокуклы документлар.

39. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар формалары турында мәгълүмат әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында бирелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

Административ процедуралар исемлеге

40. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;
2) ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш;
3) комиссия утырышын үткәрү;
4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш

41. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алу өчен «Ведомствоара электрон үзара бәйләнешнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрергә кирәк:

1) «Яшәү (тору) урыны турында белешмә». Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Эчке эшләр министрлыгы» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра;

2) «Россия Федерациясе гражданины паспортының сериясе һәм номеры буенча гамәлдә булуын тикшерү». Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Эчке эшләр министрлыгы» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

3) « Килү урыны, яки яшәү урыны буенча теркәлгән, шулай ук бер адрес буенча бергәләп миграция исәбендә торучы затлар турында белешмә». Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Эчке эшләр министрлыгы» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

42. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алу өчен башка сервислар аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрү кирәк:

1) «Репрессияләр кулланылганчы яшәгән Татарстан Республикасы җирлекләренә һәм торак пунктларына яшәү өчен кире кайткан очракта репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән затларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, шулай ук репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан,репрессияләр кулланылганчы яшәгән Татарстан Республикасы җирләренә һәм торак пунктларына яшәү өчен кире кайткан очракта репрессияләнгән затлар белән бергә репрессияләр кулланылганчы яшәгән реабилитацияләнгән затларның гаилә әгъзалары һәм башка туганнары, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән затларның ирегеннән мәхрүм итү урыннарында, сөргендә, махсус поселениедә туган балалары, әгәр алар репрессияләр кулланылганчы ата-аналары яшәгән Татарстан Республикасы җирләренә һәм торак пунктларына яшәү өчен кире кайткан очракта, торак урыннары белән тәэмин итү хокукын элек гамәлгә ашыру турында белешмәләр».

Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә соратып алына;

2) «Ышанычнамәне бирү факты һәм эчтәлеге турында белешмәләр». Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта «Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

3) «Билгеләнү турында опека органы актыннан белешмәләр». Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Комиссия утырышын үткәрү

43. Комиссия утырышы административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазифаи зат – «Зеленодольск муниципаль районы Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлеге белгече инициативасы белән башланып җибәрелә һәм Регламентның 41-42 пунктларында билгеләнгән административ процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үткәрелә.

44. Комиссия утырышын үткәрү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

а) реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу турында карар;

б) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

45. Регламентның 3 нче кушымтасында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазифаи зат – «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлеге белгече Регламентның 43-44 пунктларында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерли.

46. Регламентның 3 нче кушымтасында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазифаи зат – «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлеге белгече Регламентның 43-44 нче пунктларында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу турында карар әзерли.

Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

47. Хезмәт нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүче Регламентның 45-46 пунктларында билгеләнгән процедураны үтәү тәмамланган көнне бирелә.

48. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысулы буларак Бердәм, Республика порталын сайлаган очракта, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә яшәү урынына яисә килү урынына яисә булу урынына бәйсез рәвештә күрсәтелә

## IV.Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

49. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүче әлеге Регламент белән билгеләнгән хезмәт күрсәтүгә гариза статусын үзгәртү турында (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу турында), шулай ук мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең бирелгән этабында башкарырга тиешле алдагы адымнар һәм гамәлләр турында, санап үтелгән ысулларның берсе белән хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат бирү юлы белән;

– Бердәм портал ярдәмендә;

– Республика порталы ярдәмендә;
– башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № | Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билге атамасы | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билге идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Реабилитацияләнгән гражданнарны торакка мохтаҗ буларак исәпкә алу | Россия Федерациясенең «Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге №1761-1 номерлы Законы нигезендә торак урыннар алу хокукы булган гаилә әгъзалары исеменнән гариза белән мөрәҗәгать иткән Татарстан Республикасы территориясендә (репрессия кулланылганчы үзе яшәгән урыннарга һәм торак пунктларга) элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессиягә бәйле рәвештә торак урынын югалткан Татарстан Республикасында торучы | 1А |
| 2. | | Мөрәҗәгать итүче вәкиле | 2А |

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

**Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А, 2А | Гариза (5 нче кушымта) | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган | Башкарма комитет, КФҮ |
| 3. | 2А | Мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 1А, 2А | Реабилитация турында документлар | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |
| 5. | 1А, 2А | Репрессияләр белән бәйле рәвештә торак урынын югалту фактын раслый торган документлар | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |
| 6. | 1А, 2А | Граждан һәм аның гаилә әгъзалары итеп күрсәтелгән затлар белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар (булган очракта), яисә аларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |
| 7. | 1А, 2А | Репрессияләр кулланылганчы репрессияләнгән затның гаилә әгъзаларының һәм башка туганнарының элекке яшәү урыны адресын һәм репрессияләнгән зат белән бергә яшәү фактын раслый торган документлар (репрессияләр кулланылганчы репрессияләнгән затлар белән бергә яшәгән реабилитацияләнгән затларның гаилә әгъзалары һәм башка туганнары өчен) | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |
| 8. | 1А, 2А | Яшәү урыннарыннан куылу, иректән мәхрүм итү урыннарына , сөрген, сөрелү һәм махсус поселениегә җибәрү фактын раслый торган документлар | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |
| 9. | 1А, 2А | Иректән мәхрүм итү урыннарында, сөргендә, сөрелүдә, махсус поселениедә туу фактын раслый торган документлар (иректән мәхрүм | Бердәм портал,<br>Республика порталы,<br>Башкарма комитет, КФҮ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | итү урыннарында, сөргендә, сөрелүдә, махсус поселениедә туган балалар өчен) | |
| 10. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать итүче һәм һәр гаилә әгъзасы өчен персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (6 нчы кушымта) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итә ала торган документлар* | | | |
| 1. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать итүче һәм/яки аның гаилә әгъзалары өчен бракка керү факты булган очракта язылышу турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А, 2А | Ата булуны билгеләү факты булганда ата булуны билгеләү турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 3. | 1А, 2А | Әгәр аерылышу вакытыннан 5 ел узмаса, күрсәтелгән чорда аерылышу факты булса, бракны өзү турында таныклык; | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 1А, 2А | Фамилия, исем, атасының исемен үзгәрү факты булганда фамилияне, исемне, атасының исемен үзгәртү турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 5. | 1А-4А, 1Б-4Б | Үлем факты булганда, гаилә составын раслау өчен үлем турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 6. | 1А-4А, 1Б-4Б | Опекун билгеләү турында опека һәм попечительлек органы актыннан белешмәләр | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 7. | 1А-4А, 1Б-4Б | Яшәү (булу)урыны турында белешмәләр | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 8. | 1А, 2А | Чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 9. | 1А, 2А | Граждан хәле актларын рәсмиләштерү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 10. | 1А, 2А | Күрсәтелгән суд карары булганда мөрәҗәгать итүчегә һәм/яисә мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларына карата туганлык мөнәсәбәтләрен билгеләү яисә туктату, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, вафат булган дип тану, хәбәрсез югалган дип тану турында законлы көченә кергән суд карары (суд карарын кабул иткән суд тарафыннан таныкланган күчермә) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

**Документларны кабул итүдән баш тарту һәм**
**муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны |
|---|---|---|
| | | *Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр* |
| 1. | 1А, 2А | Муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүче тарафыннан регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау |
| 2. | 1А, 2А | Дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматларны, эчтәлеген төгәл аңларга мөмкинлек бирми торган төзәтүләрне, бозуларны үз эченә алган документлар, гамәлдән чыккан документлар тапшыру |
| 3. | 1А, 2А | Регламент нигезендә муниципаль хезмәтне алучы булмаган заттан муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү я мөрәҗәгать итүче исеменнән моңа вәкаләт бирелмәгән зат тарафыннан гариза бирү я ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турындагы белешмәләр расланмау |
| 4. | 1А, 2А | Документларның тиешле булмаган органга тапшырылуы |
| 5. | 1А, 2А | Гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны корректлы тутырмау, электрон формада һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу |
| 6. | 1А, 2А | Электрон формадагы гариза һәм башка документлар, гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган |
| 7. | 1А, 2А | Документ текстын тулы күләмдә укырга һәм (яисә) документның реквизитларын танырга мөмкинлек бирми торган электрон документлар (документларның электрон образларын) тапшыру |
| | | *Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр* |
| 1. | 1А, 2А | Татарстан Республикасында реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу хокукын расламый торган документлар һәм белешмәләр алу |
| 2. | 1А, 2А | Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның булмавы яисә аларны тутыруның тулылыгы; |
| 3. | 1А. 2А | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат ачыклану; |

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

(Форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында**
**КАРАР**

_______________________________________________________________

( мөрәҗәгать итүче- физик затның Ф. И. Ат.и., юридик затның исеме )
мөрәҗәгате белән бәйле рәвештә,

(гариза_________________ел № ______)
_______________________________________________________________
турында,_______________________________________________________
нигезендә тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны я муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм хаталарны төзәтү өчен кирәкле документларны я дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:
1.______________________________________________________________
2.______________________________________________________________

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Вазифаи зат (Ф.И.Ат.и.) _______________________________

(имза салуны гамәлгә ашыручы Башкарма комитетның вазыйфаи заты имзасы)

Башкаручы (Ф.И.Ат.и.)
_______________________________

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

(Форма)

___________________________________
__________________________________
___________________________________
_________________________________
(кемгә: вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Кемнән
___________________________________
_________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) тутырып)
___________________________________
___________________________________
(шәһәрдә, поселокта, авылда түбәндәге адрес яшәүче)
___________________________________
__________________________________
(почта индексы, тулы адресы, контакт телефоны)
___________________________________
___________________________
___________________________________
___________________________________
(көне, ае, елы)

**ГАРИЗА**

Мине,___________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта))
торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алуыгызны сорыйм, паспорт: серия _____________ N ___________, бирелгән ______________________________________ "___"______ 20__ ел, гаиләнең түбәндәге составы белән (репрессияләр кулланылганчы бергә яшәгән һәм хәзерге вакытта яшәүче гаилә әгъзалары һәм башка туганнары күрсәтелә):
1.______________________________________________________________________,
___________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), туу датасы) паспорт: серия _________ N __________, бирелгән _____________________ "___"______ 20__ ел, яшәү адресы: ______________________________.

2..__________________________________________________________________,
___________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), туу датасы) паспорт: серия _________ N __________, бирелгән _____________________ "___"_______ 20__ ел, яшәү адресы: ______________________________.
3..__________________________________________________________________,
___________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), туу датасы) паспорт: серия _________ N __________, бирелгән _____________________ "___"_______ 20__ ел, яшәү адресы: ______________________________

Гаризага түбәндәге документларны терким:

1) __________________________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

2)________________________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

3)________________________________________________________________________;

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

4)_________________________________________________________________________

(документның исеме һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Гариза каралу нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйбыз:

 электрон рәвештә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының шәхси кабинетында;

 Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетта электрон рәвештә;

 күпфункцияле үзәктә;

 электрон документны e-mail адресына җибәрү юлы белән:_______________;

 кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адрес буенча: ___________________________________________________________________________.

Мөрәҗәгать итүче:_____________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча, имза)

Хокукка сәләтле гаилә әгъзалары:

1.______________________________________________________________

2.______________________________________________________________

3.______________________________________________________________

4.______________________________________________________________

(гаиләнең эшкә сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

«_____» _________________________ 20____ ел.

(дата сүз белән языла)

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

(Форма)

Кемнән_____________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме)
__________________________________________________
(шәхесне таныклаучы документ: серия, номер,
_________________________________________________
кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
_______________________________________________,
түбәндәге адрес буенча теркәлгән:
_____________________________________________________
_____ ___________, ________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме)
________________________________________________,
________________________________________________,
(шәхесне таныклаучы документ: серия, номер,
_________________________________________________
кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
_________________________________________________,
адрес буенча теркәлгән:
__________________________________________________
_________________________________________________,
Нигез_____________________________________ (документ – нигез: серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
__________________________________________________
_____________________________________________________
–
Элемтә телефоны__________________________________

**Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин,
_______________________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме)
_______________________________________________________________өчен эшләүче
(фамилия, исем, атасының исеме)
____________________________________________________________________________,

ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә ризалык бирәм ______________________________________________________________________

______________________________________________________________

автоматлаштыру чараларын кулланып яисә мондый чараларны кулланмыйча башкарыла торган телләсә нинди гамәлне (операцияне) яисә гамәлләр (операцияләр) җыелмасын, шул исәптән җыюны, язып алуны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны,үзгәртүне), алуны, куллануны, тапшыруны (таратуны), бирүне, керүне, шәхессезләндерүне, блоклауны, бетерүне, юк итүне) түбәндәге персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (операциягә):

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, гражданлыгы;

яшәү урыны буенча теркәлү адресы һәм фактта яшәү адресы;

Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документ (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);

гаилә хәле турында белешмәләр;

электрон почта адресы, электрон почта булмаган очракта-почта адресы;

контакт телефоны номеры (булган очракта) һәм башка мәгълүматлар ____________________________________________________________ .

Югарыда күрсәтелгән персональ мәгълүматлар реабилитацияләнгән гражданнарны Татарстан Республикасында торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында эшкәртү ӧчен бирелә.

Әлеге ризалыкның гамәлдә булу вакыты □чикләнми.

Мин түбәндәгеләр белән таныштым: персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык, әлеге ризалыкка кул кую датасыннан алып операторның бөтен срогы дәвамында һәм ул тәмамланганнан соң гамәлдә була; персональ мәгълүматлар эшкәртеләчәк

______________________________________________________________________

(муниципаль берәмлек органының адресы) ______________________________________________________________________;

персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Россия Федерациясе законында билгеләнгән әлеге ризалык минем почта аша оператор адресына язган язма гаризам буенча заказлы хат белән теләсә кайсы вакытта кире алынырга мөмкин. Ризалыкны кире алу законнар нигезендә язма рәвештә башкарыла дипраслыйм. Ризалыкны кире алуның тискәре нәтиҗәләре өчен бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам. Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, оператор «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152 – ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 2-11 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булганда персональ белешмәләрне эшкәртүне ризалыктан башка дәвам итәргә хокуклы;

өченче затларга карата бирелә торган персональ мәгълүматлар Россия Федерациясе законнары белән операторга йөкләнгән функцияләрне, вәкаләтләрне һәм бурычларны гамәлгә ашыру һәм үтәү максатларында гына эшкәртеләчәк

____________________________________________________________

(имза) (фамилия, исем, атасының исеме)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________ өчен эшләүче,

(имза) (фамилия, исем, атасының исеме)

______________________________________________________________________.

Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

(Форма)

(Башкарма комитет бланкы)

**КАРАР**

Яшәү урынына мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу турында

(ФИАт.и., туган көне) тарафыннан (теркәлгән адресы) адресы буенча теркәлгән, яшәү урынына мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданин буларак исәпкә алуның үтенечен һәм документларын карап, «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 номерлы РФ Законының 13 ст.., «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2025 елның 29 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы ТР Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Торак урыннарына мохтаҗ буларак реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу һәм исәпкә алу тәртибен раслау турында” 2025 елның 29 ноябрендәге 1018 номерлы карарының 2.3 п. 2 нче өлеше нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты __________ № ___ карары белән расланган, Татарстан Республикасында торак урыннарга мохтаҗ буларак реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия карары белән _________№ беркетмә буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Торак урын бирелүгә мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданнар буларак исәпкә (ФИАт.и., туган дата) кабул итәргә.
2. «Зеленодольск муниципаль районы Торак сәясәте департаменты» МКУга (ФИАт.и.) һәм аның гаилә әгъзаларына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урын бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә алыну турында хәбәр итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

Вазифаи зат (Ф.И.Ат.и.)

(имза салуны гамәлгә ашыручы
Башкарма комитетның вазыйфаи
заты имзасы)

Репрессияләр нәтиҗәсендә яшәү урыннарын югалткан һәм элекке яшәү урынына Татарстан Республикасы территориясенә кайткан реабилитацияләнгән гражданнарны яшәү урынына мохтаҗ булып исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына
8 нче кушымта

(Форма)

(Башкарма комитет бланкы)

**КАРАР**

Яшәү урыны бирү өчен мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алудан баш тарту турында

(ФИАт.и., туган көне) тарафыннан (теркәлгән адресы) адресы буенча теркәлгән, яшәү урынына мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданин буларак исәпкә алуның үтенечен һәм документларын карап, «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 номерлы РФ Законының 13 ст.., «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2025 елның 29 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы ТР Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Торак урыннарына мохтаҗ буларак реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу һәм исәпкә алу тәртибен раслау турында” 2025 елның 29 ноябрендәге 1018 номерлы карарының 2.3 п. 2 нче өлеше нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты __________ № ___ карары белән расланган, Татарстан Республикасында торак урыннарга мохтаҗ буларак реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия карары белән _________№ беркетмә буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Торак урын бирелүгә мохтаҗ реабилитацияләнгән гражданнар буларак исәпкә (ФИАт.и., туган дата) алудан баш тартырга.
2. «Зеленодольск муниципаль районы Торак сәясәте департаменты» МКУга (ФИАт.и.) һәм аның гаилә әгъзаларына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урын бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә алыннан баш тарту турында хәбәр итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Электрон имза турында белешмәләр

Вазифаи зат (Ф.И.Ат.и.)

(имза салуны гамәлгә ашыручы
Башкарма комитетның вазыйфаи
заты имзасы)